ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
23.07.2018 № 18

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Пыжмара авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планы проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 28 статьялары, «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гавами тыңлаулар турында нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Пыжмара авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә кешенең уңай тормыш шартларына хокукын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча Пыжмара, Сәрдек һәм Иске Пукшинер авыллары гражданнары катнашында гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны Пыжмара, Сәрдек һәм Иске Пукшинер авыллары гражданнары өчен 2018 елның 25 августында 9.00 сәгатьтә Пыжмара мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Балтач районы, Пыжмара авылы, С.Мөлеков урамы, 19 нчы йорт.

3. «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны Әтнә һәм Югары Сәрдек авыллары гражданнары өчен 2018 елның 25 августында 10.00 сәгатьтә Әтнә мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Балтач районы, Әтнә авылы, Комсомол урамы, 22 нче йорт.

4. Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү буенча комиссиягә (алга таба - Комиссия) гавами тыңлаулар үткәрүне оештырырга.

5. Комиссиягә «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы демонстрацион материалларыннан күргәзмә-экспозицияләр оештырырга, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

6. Генераль план проекты буенча гражданнардан киңәшләр һәм тәкъдимнәр бер ай дәвамында Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Пыжмара авылы, С.Мөлеков урамы, 19 нчы йорт.

7. Әлеге карарны baltasi.tatar.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче __________________Р.Х. Җәләев